ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**Чистай шәһәре**

**2025 елның 13 августы** **№ 379**

Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең финанс органнары тарафыннан казначылык хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 24 июнендәге 158-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 13 июлендәге 177-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең финанс органнары тарафыннан казначылык хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 22 мартындагы 206 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең финанс органнары тарафыннан казначылык хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыру тәртибенә (алга таба текст буенча - тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 1 абзацында «1 пунктның 1 пунктчасы нигезендә» сүзләренннән соң «Бюджет кодексының 1 статьясы…» сүзләрен «Бюджет кодексының 242.26 статьясы…» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 10 пунктның 7 абзацын «гуманитар ярдәм,» сүзләренннән соң «халыкны яклауны тәэмин итү,» сүзләрен өстәргә, «аларны китереп чыгардылар» сүзләренннән соң «яки китерергә мөмкиннәр» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"да (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (http://chistopol.tatarstan.ru/) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов